**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының**
**Поручик авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

**10.12.2020** **№16**

**«Җир салымы турында» 2014 елның 14 ноябрендәге 119 номерлы Зәй муниципаль районының Поручик авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында»**

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә, шулай ук Зәй муниципаль районы Поручик авыл җирлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районының Поручик авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Җир салымы турында» 2014 елның 14 ноябрендәге 119 номерлы Зәй муниципаль районының Поручик авыл җирлеге Советы карарына (12.09.2015 ел, №149, 16.11.2015 ел, №12, 25.09.2017 ел, №84, 23.03.2018 ел, № 106 карарлары редакциясендә)

1.1. 1 пунктта:

а) 1.1.2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1.2. шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә кулланылмый торган;»

б) 1.2.5 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2.5.торак фонды һәм торак-коммуналь комплексы инженерлык инфраструктурасы объектлары алып торган (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктагы өлештән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) (эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш);»

1.2. 3 пунктта 3.2 пунктчасы үз көчен югалткан дип таныrга.

1.3. 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Салым ташламалары хокукына ия салым түләүчеләр салым органына үз теләге белән салым ташламасы бирү турында гариза язалар, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы документларны тапшырырга хокуклы.

1.4. 7 пунктны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карар, үз көченә керүнең башка сроклары билгеләнгән пунктлардан тыш, басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарның 1 пунктындагы 1.2, 1.4 пунктчалары 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Карарны мәгълүмат стендларында, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районы сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Совет рәисе,**
**Поручик авыл җирлеге**
**башлыгы** **П.В. Тимаськов**